**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕСОВЕТЫ**

**КАРАР**

**№ 22 Иске Каразирек ав. «20» октябрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегеСоветының 2023 елның 31 маендагы 8 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Иске Каразирек авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Советының 2023 елның 31 маендагы 8 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Исе Каразирек авыл җирлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 17 маддәсенең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме Россия Федерациясе Хөкүмәте, муниципаль берәмлек Башкарма комитеты билгеләгән дәүләт (муниципаль) программалары исемлеге һәм структурасы нигезендә, бюджет чыгымнарының максатчан маддәсе буенча һәр программа буенча бюджет турында карар белән раслана.

Чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителгән муниципаль программалар, шулай ук элек расланган муниципаль программаларга үзгәрешләр җирлек башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнгән вакыт аралыгында расланырга тиеш.

Муниципаль программалар бюджет турында карар үз көченә кергән көннән алып өч айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

1.2. Нигезләмәнең 16 маддәсенең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеге муниципаль программалар, шулай ук муниципаль программаларга карамаган эшчәнлек юнәлешләре буенча җирлекнең башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә формалаштырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында тъбщндщге электрон адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы

Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә тъбщндщге электрон адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Э.М.Минниярова